КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 21 май г.Казань № 357

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы карамагындагы белем бирү оешмалары, социаль хезмәт күрсәтү оешмалары, спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы оешмалар, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округларының мәгариф оешмаларын һәм спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы оешмалары хезмәткәрләренә мәҗбүри башлангыч, кабатланып тора торган медицина карауларын (тикшерүләрен) үткәрүне оештыру турында» 2013 ел, 14 май, 325 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы карамагындагы белем бирү оешмалары, социаль хезмәт күрсәтү оешмалары, спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы оешмалар, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округларының мәгариф оешмаларын һәм спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы оешмалары хезмәткәрләренә мәҗбүри башлангыч, кабатланып тора торган медицина карауларын (тикшерүләрен) үткәрүне оештыру турында» 2013 ел, 14 май, 325 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 21 октябрь, 782 нче; 2013 ел, 31 декабрь, 1113 нче; 2014 ел, 6 август, 574 нче; 2014 ел, 26 ноябрь, 916 нчы; 2018 ел, 9 апрель, 216 нчы; 2020 ел, 25 август, 739 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 213 статьясындагы дүртенче өлешендә каралган хезмәткәрләрне мәҗбүри башлангыч һәм кабатланып тора торган медицина карауларын үткәрү тәртибен, зарарлы һәм (яки) куркыныч җитештерү факторлары булган эшләрне, шулай ук мәҗбүри башлангыч һәм кабатланып тора торган медицина караулары үткәрелә торган эшләрне башкаруга карата медицина ягыннан зарарлы булуын күрсәтә торган билгеләр исемлеген раслау турында» 2021 елның 28 гыйнварындагы 29н номерлы боерыгы белән расланган Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 213 статьясындагы дүртенче өлешендә каралган хезмәткәрләрне мәҗбүри башлангыч һәм кабатланып тора торган медицина карауларын үткәрү тәртибе нигезендә Татарстан Республикасы оешмалары хезмәткәрләренә медицина карауларын оештыруны һәм үткәрүне тикшерүдә тотуны;»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы карамагындагы белем бирү оешмалары, социаль хезмәт күрсәтү оешмалары, спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы оешмалар, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округларының белем бирү оешмаларын һәм спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы оешмалары хезмәткәрләренә мәҗбүри башлангыч, кабатланып тора торган медицина карауларын үткәрүне оештыру чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү тәртибенең 4 нче пунктында «Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының «Зарарлы һәм (яки) куркыныч җитештерү факторлары һәм мәҗбүри башлагыч һәм даими медицина караулары (тикшерүләре) үткәрелә торган эшләр исемлеген һәм Авыр эшләрдә һәм зарарлы һәм (яисә) куркыныч хезмәт шартлары булган эшләрдә эшләгән хезмәткәрләргә мәҗбүри башлангыч һәм даими медицина карауларын (тикшерүләрен) үткәрү тәртибен раслау турында» 2011 елның 12 апрелендәге 302н боерыгы» сүзләрен «Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының «Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 213 статьясындагы дүртенче өлешендә каралган хезмәткәрләрне мәҗбүри башлангыч һәм кабатланып тора торган медицина карауларын үткәрү тәртибен, зарарлы һәм (яки) куркыныч җитештерү факторлары булган эшләрне, шулай ук мәҗбүри башлангыч һәм кабатланып тора торган медицина караулары үткәрелә торган эшләрне башкаруга карата медицина ягыннан зарарлы булуын күрсәтә торган билгеләр исемлеген раслау турында» 2021 елның 28 гыйнварындагы 29н номерлы боерыгы» сүзләренә алмаштырырга.

2. Бу карарның гамәле 2021 елның 1 апреленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин